РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬКЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422870, с.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛКИ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422870, РТ БазарлыМатакавылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

31.08.2018 г.№ 339

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ
# КАРАР

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Әлки муниципаль районында гражданлык хәле актларын теркәүне нәтиҗәле оештыру максатларында:

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге турында Нигезләмәне раслау хакында (кушымта).

2.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 29 декабрендәге 337 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге турындагы нигезләмәне үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге җитәкчесе Хәлиуллина Э. Ф. йөкләргә.

Әлки муниципаль районы Башкарма
комитеты җитәкчесе Йосыпов И.В.

Расланган

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы

Башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан

_________елның ________№ карары

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ ГРАЖДАНЛЫК ХӘЛЕ АКТЛАРЫН ТЕРКӘҮ БҮЛЕГЕ ТУРЫНДА НИГЕЗЛӘМӘ.

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1 Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге (алга таба - Бүлек) Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга тапшырылган федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру максатларында "Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының структур бүлекчәсе булып тора.

1.2 Үз эшчәнлегендә бүлек Россия Федерациясенең халыкара хокукның һәм халыкара шартнамәләрнең гомумтанылган принципларына һәм нормаларына, Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, Россия Федерациясе Гражданнар кодексына, Россия Федерациясенең Гаилә кодексына, "Граждан хәле актлары турында" 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясенең башка федераль законнарына һәм аның нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясе норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә таянып эш итә, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасының башка законнары һәм алар нигезендә кабул ителә торган Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының башка хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3. Бүлек үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча вәкаләтле органы, федераль башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка башкарма органнары һәм Россия

Федерациясенең башка субъектларының дәүләт хакимияте органнары белән үзара бәйләнештә торып эшчәнлек алып бара.

1.4. Бүлек мөстәкыйль юридик зат булып тормый.

1.5. "Гражданлык хәле актлары турында" 1997 елның 15 ноябрендәге 143-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә бүлекнең үз эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе Дәүләт гербы сурәте белән билгеләнгән үрнәктәге штамп һәм бланклары бар.

1.6. Бүлекне финанслау җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджеты составында Компенсацияләрнең төбәк фондыннан субвенцияләр исәбенә бирелә торган чыгымнар сметасы һәм штат расписаниесе нигезендә башкарыла.

1.7. Бүлекнең тулы исеме: Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының Гражданлык хәле актларын теркәү бүлеге.

1.8. Бүлекнең кыскартылган исеме: Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге.

1.9. Бүлекнең урнашкан урыны: 422870, Татарстан Республикасы, Әлки районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов урамы, 55 нче йорт.

## 2. Бүлекнең Бурычлары.

2.1. Бүлекнең төп бурычы булып гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының җирле үзидарә органнарына "Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында" 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә тапшырылган гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен тиешенчә башкаруны тәэмин итү тора.

## 3. Бүлекнең Функцияләре.

3.1. Бүлек үз компетенциясе кысаларында әлеге Нигезләмәнең 2.1 пункты нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

3.1.1. Законнар җыелмасында билгеләнгән тәртиптә гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны башкара: гражданнарның милек һәм шәхси мөлкәткә карамаган хокукларын, шулай ук дәүләт мәнфәгатьләрен саклау максатларында, туу, никах, аерылышу, уллыкка (кызлыкка) алу, исемне үзгәртү, үлем.

3.1.2. Гражданлык хәле актларын язганда Федераль законнарда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә төзәтүләр һәм үзгәрешләр кертә.

3.1.3. Законлы көченә кергән суд карарлары нигезендә Граждан хәле актлары язмаларын яңадан торгыза һәм юкка чыгара.

3.1.4. Федераль законнар тарафыннан билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә башка юридик әһәмиятле гамәлләр кыла, шул исәптән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында кабат таныклыклар һәм Гражданлык хәле актлары турында белешмәләр бирүне, Гражданлык хәле актлары язмаларының булмавы турында хәбәр бирүне гамәлгә ашыра; пособиеләр билгеләү һәм түләү өчен белешмәләр бирүне башкара.

3.1.5. Бүлектә эш башкаруны Россия Федерациясе законнары нигезендә, шул исәптән "Татарстан Республикасының Граждан хәле актларын теркәүнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы (АИС ЗАГС РТ)"дәүләт мәгълүмат системасы чараларын кулланып алып бара.

3.1.6. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына Татарстан Республикасы ЗАГС органнары тарафыннан бирелгән һәм Россия Федерациясе территориясеннән читтә файдалану өчен билгеләнгән документларда "апостиль" штампын кую өчен бүлек хезмәткәрләре имзалары үрнәкләрен тәкъдим итә,

3.1.7. Россия Федерациясе салым законнарының Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлешендә үтәлешен һәм ЗАГС органнары тарафыннан башкарылучы башка юридик әһәмиятле гамәлләр үтәлешен тәэмин итә; үз карарын формалаштыра һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә дәүләт пошлинасының артык түләнелгән суммасын кире кайтару турында материалларны җибәрә

3.1.8. Билгеләнгән тәртиптә гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык бланкларын исәпкә алуны, саклауны һәм аларны тоту турында хисап бирүне гамәлгә ашыра.

3.1.9. Бүлек тарафыннан төзелгән һәм саклана торган гражданлык хәле актлары язмаларының электрон мәгълүматлар базасын формалаштыра, акт язмаларын актуаль хәлдә тота, вакытындалыгын һәм тулылыгын тәэмин итә.

3.10. Гражданлык хәле актлары язмаларының беренче нөсхәләреннән башлап җыелган, муниципаль берәмлек территориясендә төзелеп, тегелгән, номерланган һәм мөһерләнгән кенәгәләрнең исәбен, эшкәртелүен, системалаштырылуын һәм саклануын йөз ел буе алып бара.

3.1.11. Гражданлык хәле актларының дәүләт теркәве кенәгәләрен (акт кенәгәләрен) саклау өчен тиешле шартлар оештыра.

3.1.12. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә саклау срогы вакытлыча булган документларын исәпкә алуны һәм саклауны оештыра.

3.1.13. Бүлек ел саен раслана торган номенклатура нигезендә эш алып баруны һәм формалаштыруны тәэмин итә.

3.1.14. Билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына муниципаль берәмлек территориясендә төзелгән акт язмаларының икенче нөсхәсен дәүләти теркәү мәсьәләләре буенча айлык тапшыруны оештыра, шулай ук гражданлык хәле актларын язганда үзгәрешләр һәм төзәтмәләр кертү турында хәбәр җибәрә.

3.1.15. Статистик хисаплылыкны төзи, Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча мәгълүмат ресурсы һәм башка юридик яктан әһәмиятле гамәлләр булдыра, аннан соң Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына законнар белән билгеләнгән сроклар һәм таләпләр нигезендә дәүләт теркәве мәсьәләләрен тапшыра.

3.1.16. Ведомстволар арасында мәгълүмат алмашу кысаларында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә һәм очракларда Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында хәбәр итә.

3.1.17. Чит дәүләтләрнең юстиция һәм Гражданлык хәле актларын теркәү учреждениеләренең территориаль органнары белән үз компетенциясе чикләрендә Россия Федерациясенең халыкара килешүләре белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда, шул исәптән чит дәүләтләрнең компетентлы органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә хокукый ярдәм соратып алуны һәм тапшыруны да кертеп хезмәттәшлек итә.

3.1.18. Россия Федерациясе гражданнары паспортларында никах теркәүне һәм өзүнең беренчел билгеләрен ясый, Федераль миграция хезмәтенең территориаль органына Россия Федерациясе территориясендә үлгән гражданинның паспортын соңгы яшәү яки килү урынына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә җибәрә.

3.1.19. Судларда гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча бүлек вәкилләренең катнашуын оештыра.

3.1.20. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының эшчәнлек өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салучы хокукый актлар проектларын эшләүдә катнаша һәм аларны билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына тапшыра.

3.1.21. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының хокукый актлары проектларына бәяләмәләр әзерләүдә катнаша.

3.1.22. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә хокукларны куллану тәҗрибәсен өйрәнә һәм гомумиләштерә, шул нигездә закон чыгару инициативасы хокукына ия булган субъектларга федераль һәм республика законнарын камилләштерү буенча тәкъдимнәр кертә.

3.1.23. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына бюджет чараларына булган ихтыяҗны, шул исәптән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу чараларын бюджет тарафыннан финанслау күләмнәре турында тәкъдимнәр һәм хисапларны билгеләнгән тәртиптә әзерли һәм тапшыра.

3.1.24. Контроль-күзәтчелек тикшерүләре үткәрү нәтиҗәсендә ачыкланган төгәлсезлекләрне бетерүне вакытында һәм билгеле тәртиптә башкаруны оештыра.

3.1.25. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча дәүләт хезмәтләрен, шул исәптән электрон рәвештә, күрсәтү мәсьәләләре буенча гражданнарны кабул итүне һәм консультация бирүне оештыра, шулай ук гражданнарның телдән һәм язма мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын закон нигезендә кабул итүне, үз вакытында һәм тулы күләмдә карауны, кабул ителгән карарларга аңлатма бирүне тәэмин итә; халыкка оператив хокукый хезмәт күрсәтү өчен шартлар тудыра.

3.1.26. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча гражданнарга дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкинлеген арттыруга, шул исәптән халыкка кирәкле документлар үрнәкләрен: халыкны кабул итү урыннары, вакыты, көннәре һәм сроклары турында мәгълүматны стендларында урнаштыруны тәэмин итеп, Гражданлык хәле актларын теркәү өлкәсендәге органнарының һәм шул сферада эшләүче югары органнарның адресларын күрсәтеп, шулай ук электрон, контакт телефоннарын да кертеп кирәкле чаралар күрә.

3.1.27. Гражданнар хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендә гражданнарның хокукларын тәэмин итү мәсьәләләре буенча халык арасында массакүләм мәгълүмат чаралары аша, район халкы белән очрашулар вакытында һәм башка формаларда аңлату эшләре алып бара, хокукый ярдәм күрсәтә.

3.1.28. Эшчәнлек өлкәсенә туры килгән җәмәгать берләшмәләренә билгеләнгән тәртиптә ярдәм күрсәтә.

3.1.29. Муниципаль берәмлекнең рәсми сайты составындагы бүлекнең Интернет-сәхифәсен алып бара һәм актуаль хәлдә тота, шулай ук гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының рәсми сайтында урнаштыру өчен мәгълүмат бирә.

3.1.30. Гаилә сәясәтен тормышка ашыру кысаларында Гаилә-никах мөнәсәбәтләрен ныгытуга, гаилә кыйммәтләрен һәм милли гореф-гадәтләрне популярлаштыруга юнәлдерелгән чаралар үткәрә: аерым алганда, "никахлашу", "исем кушу" тантаналы церемонияләре, гаилә тормышы юбилярларын хөрмәтләү, һөнәри осталык конкурслары һ. б. чаралар үткәрә.

3.1.31. Имин хезмәт шартларын, хезмәтне саклау һәм янгын куркынычсызлыгы нормалары һәм кагыйдәләре үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыра.

3.1.32. Бүлекнең материаль-техник базасының сакланышын тәэмин итә.

3.1.33. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга бәйле рәвештә, бүлек хезмәткәрләренә билгеле булган конфиденциаль Шәхси мәгълүматларны, законнар белән билгеләнгән тәртиптә яклауны, чикләүне һәм фаш итмәүне тәэмин итә,

3.1.34. Билгеләнгән компетенция кысаларында Бүлекнең төп бурычларын үтәү өчен башка функцияләрне гамәлгә ашыра.

## 4. Бүлекнең Хокуклары.

4.1. Үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашыру өчен бүлек хокуклы:

4.1.1. Әлки муниципаль районы җирле үзидарә һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан кирәкле мәгълүматны соратып алырга.

4.1.2. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга тапшырылган вәкаләтләрне үтәү, матди-техник базасын ныгыту һәм үстерү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм бюджеттан тыш чыганаклардан алынган субвенцияләрне куллану буенча законнарда билгеләнгән тәртиптә файдалану өчен Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына тәкъдимнәрне, исәп-хисапны кертергә.

4.1.3. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитетына бүлек хезмәткәрләренең хезмәт шартларын яхшырту, җиһазлар, шул исәптән оештыру-техник һәм атрибутика белән тәэмин итү турында тәкъдимнәр кертергә.

4.1.4. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән эшләрне алып барырга яисә вәкилгә гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу белән бәйле эшләр алып баруны йөкләргә.

4.1.5. Муниципаль берәмлек территориясендә оештырыла торган киңәшмәләр, конференцияләр, семинарлар оештыруда һәм үткәрүдә, шулай ук билгеләнгән эшчәнлек өлкәсенә караган мәсьәләләр буенча республика һәм Бөтенроссия чараларында катнашырга.

4.1.6. Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өлкәсендәге мәсьәләләрне хәл итүдә ярдәм итү максатыннан оештырылган фәнни, координацион һәм консультатив органнарның эшчәнлегендә катнашу.

4.1.7. Гражданнарны кабул итү, алар буенча тиешле чаралар күрү; Бүлек компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча гражданнарны кабул итү.

## 5. Бүлекнең эшчәнлеген оештыру.

5.1. Бүлек аппаратын тотуга киткән чыгымнарның штат расписаниеse һәм сметасы Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өчен билгеләнгән санда һәм субвенциядә Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

5.2. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен башкаруы бүлек хезмәткәрләре муниципаль хезмәткәрләр булып торалар һәм әлеге Нигезләмә һәм вазыйфаи инструкцияләр нигезендә эш итәләр.

5.3. Аерым функцияләрне башкару өчен Әлки муниципаль районының муниципаль хезмәткәрләре булмаган башка хезмәткәрләр белән граждан-хокукый характердагы килешүләр төзергә мөмкин.

5.4. Бүлекне муниципаль берәмлек башлыгы һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча вәкаләтле органы белән килештереп, Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан билгеләнгән һәм вазифасыннан азат ителгән башлык җитәкли.

5.5. Бүлек җитәкчесе булмау чорында аның бурычларын үтәү Бүлекнең баш белгеченә билгеләнгән тәртиптә йөкләнә.

5.6. Бүлек хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләү һәм вазыйфадан азат итү Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан бүлек башлыгы тәкъдиме буенча башкарыла.

5.7. Бүлек җитәкчесе:

5.7.1 Бүлек эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Бүлеккә йөкләнгән бурычларны һәм функцияләрне башкаруны тәэмин итә.

5.7.2. Законнар белән билгеләнгән тәртиптә Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына бүлек хезмәткәрләрен кабул итү, күчерү, эштән азат һәм кабул итү, шулай ук кызыксындыру (бүләкләү) һәм аларга карата дисциплинар җәза куллану турында тәкъдимнәр кертә.

5.7.3. Граждан хәле актларын дәүләт теркәве мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимият органының вәкаләтле органы коллегиясе эшендә, бүлек вәкаләтләренә керә торган мәсьәләләр буенча киңәшмә, семинарлар һәм башка чараларда катнаша.

5.7.4. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу мәсьәләләре буенча семинарлар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, күргәзмәләр һәм башка чаралар оештыра.

5.7.6. Бүлек эшчәнлегенә бәйле гражданлык эшләрен караганда суд утырышларында катнаша.

5.7.7. Муниципаль берәмлек башкарма комитеты җитәкчесенә бүлек турында Нигезләмәне, хезмәткәрләрнең вазифаи инструкцияләрен әзерли һәм раслауга тапшыра.

5.7.8.Бүлекнең эш планнарын әзерләүне һәм үтәүне оештыра.

5.7.9. Үз компетенциясе кысаларында документларга имза сала һәм визалый.

5.7.10. Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2017 елның 29 декабрендәге 298 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе территориясендә гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнар тарафыннан гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу Административ регламенты таләпләре нигезендә Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуның дөреслеге һәм сыйфаты өчен персональ җавап бирә.

5.8. Бүлек эшчәнлеге белән турыдан-туры Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе идарә итә.

6. Бүлекнең милке һәм финанслары.

6.1. Бүлек эшчәнлеген финанслау 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законы нигезендә бирелә торган субвенцияләр һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы бюджетында каралган акчалар исәбенә башкарыла.

6.2. Бүлек Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешеп Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Уставында каралган очракларда һәм тәртиптә гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының матди ресурслар һәм финанс чараларын өстәмә рәвештә кулланырга хокуклы.

6.3. Бүлекнең мөлкәте булып, аңа оператив идарә хокукында тапшырылган һәм Татарстан Республикасының Әлки муниципаль районы милке булып торучы милек тора.

6.4. Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен түләүсез файдалануга тапшырыла торган кирәкле дәүләт милке һәм бүтән матди чаралар исемлеге, законнарда билгеләнгән тәртиптә тәгаенләнә.

7. Эшчәнлекне туктату һәм Бүлекне юкка чыгару.

7.1. Әгәр Татарстан Республикасы законы белән Гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырудан туктатылса, шулай ук чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турында 2005 елның 30 декабрендәге 146-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарына гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу вәкаләтләрен бирү турында" Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре үз көченә кертелмәгән очракта, Бүлек үз эшчәнлеген туктатырга һәм ликвидацияләнергә тиеш.